ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

21.05.2022 г. Казань **№** 419/2022

**Халкының исәбе биш йөз һәм аннан күбрәк кеше исәпләнгән авыл җирлекләрендә, шәһәр округларында урнашкан җылылык челтәрләреннән тыш, җылылык челтәрләре буенча җылылык энергиясе, җылылык энергиясен саклый торган матдә тапшырылганда технологик югалту нормативларын раслау буенча Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында**

«Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларын көчен югалткан дип тану турында» 2022 елның 28 февралендәге 175 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә боерык бирәм:

1. Халкының исәбе биш йөз һәм аннан күбрәк кеше исәпләнгән авыл җирлекләрендә, шәһәр округларында урнашкан җылылык челтәрләреннән тыш, җылылык челтәрләре буенча җылылык энергиясе, җылылык энергиясен саклый торган матдә тапшырылганда технологик югалту нормативларын раслау буенча Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын расларга.

2. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының түбәндәге боерыкларын үз көчен югалткан дип танырга:

«Халкының исәбе биш йөз һәм аннан күбрәк кеше исәпләнгән авыл җирлекләрендә, шәһәр округларында урнашкан җылылык челтәрләреннән тыш, җылылык челтәрләре буенча җылылык энергиясе, җылылык энергиясен саклый торган матдә тапшырылганда технологик югалту нормативларын раслау буенча Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2019 елның 20 августындагы 206 номерлы;

«Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2019 елның 20 августындагы 206 номерлы боерыгы белән расланган Халкының исәбе биш йөз һәм аннан күбрәк кеше исәпләнгән авыл җирлекләрендә, шәһәр округларында урнашкан җылылык челтәрләреннән тыш, җылылык челтәрләре буенча җылылык энергиясе, җылылык энергиясен саклый торган матдә тапшырылганда технологик югалту нормативларын раслау буенча Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертү турында» 2019 елның 30 ноябрендәге 401 номерлы;

«Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2019 елның 20 августындагы 206 номерлы боерыгы белән расланган Халкының исәбе биш йөз һәм аннан күбрәк кеше исәпләнгән авыл җирлекләрендә, шәһәр округларында урнашкан җылылык челтәрләреннән тыш, җылылык челтәрләре буенча җылылык энергиясе, җылылык энергиясен саклый торган матдә тапшырылганда технологик югалту нормативларын раслау буенча Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 22 июлендәге 276/2020 номерлы;

«Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2019 елның 20 августындагы 206 номерлы боерыгы белән расланган Халкының исәбе биш йөз һәм аннан күбрәк кеше исәпләнгән авыл җирлекләрендә, шәһәр

округларында урнашкан җылылык челтәрләреннән тыш, җылылык челтәрләре буенча җылылык энергиясе, җылылык энергиясен саклый торган матдә тапшырылганда технологик югалту нормативларын раслау буенча Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 23 декабрендәге 723/2020 номерлы;

«Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2019 елның 20 августындагы 206 номерлы боерыгы белән расланган Халкының исәбе биш йөз һәм аннан күбрәк кеше исәпләнгән авыл җирлекләрендә, шәһәр округларында урнашкан җылылык челтәрләреннән тыш, җылылык челтәрләре буенча җылылык энергиясе, җылылык энергиясен саклый торган матдә тапшырылганда технологик югалту нормативларын раслау буенча Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 26 октябрендәге 597/2021 номерлы.

3. Әлеге боерык рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге Боерык үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары С.В.Павловка йөкләргә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт
комитетының 2022 елның
21 май №419/2022 номерлы
боерыгы белән расланды

**Халкының исәбе биш йөз һәм аннан күбрәк кеше исәпләнгән авыл җирлекләрендә, шәһәр округларында урнашкан җылылык челтәрләреннән тыш, җылылык челтәрләре буенча җылылык энергиясе, җылылык энергиясен саклый торган матдә тапшырылганда технологик югалту нормативларын раслау буенча Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Регламент халкының исәбе биш йөз һәм аннан күбрәк кеше исәпләнгән авыл җирлекләрендә, шәһәр округларында урнашкан җылылык челтәрләреннән тыш, җылылык челтәрләре буенча җылылык энергиясе, җылылык энергиясен саклый торган матдә тапшырылганда технологик югалту нормативларын раслау буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба – дәүләт хезмәте) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр: җылылык энергиясен тапшыру һәм бүлү буенча хезмәтләр күрсәтүче, үзенә карата бәяләрне (тарифларны) дәүләти җайга салу гамәлгә ашырыла торган юридик затлар яки шәхси эшкуарлар, халкы биш йөз мең һәм аннан күбрәк кеше исәпләнгән җирлекләрдә, шәһәр округларында урнашкан җылык челтәрләренә милекчелек хокукында яки законлы бүтән нигезләрдә ия булган юридик затлардан һәм шәхси эшкуарлардан тыш.

1.3. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә (мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү варианты нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган үткәрә торган анкета нәтиҗәсендә билгеләнгән мөрәҗәгать итүченең тиешле билгеләренә туры килә торган дәүләт хезмәте күрсәтү) профильне яңасына үзгәртү үткәрелми.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Күрсәтелә торган дәүләт хезмәте атамасы.

Халкының исәбе биш йөз һәм аннан күбрәк кеше исәпләнгән авыл җирлекләрендә, шәһәр округларында урнашкан җылылык челтәрләреннән тыш, җылылык челтәрләре буенча җылылык энергиясе, җылылык энергиясен саклый торган матдә тапшырылганда технологик югалту нормативларын раслау.

2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның исеме.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәктә (алга таба –

күпфункцияле үзәк), шулай ук күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урынында дәүләт хезмәте күрсәтү каралмаган.

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе.

2.3.1. Җылылык энергиясен тапшырганда, җылылык челтәрәре буйлап җылылык җиткерү матдәсен тапшырганда технологик югалту нормативларын раслау турында боерык яки нормативларны раслаудан баш тарту турында белдерү.

2.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе аны алу буенча сайланган ысул белән мөрәҗәгать итүчегә бирелә (җибәрелә):

язмача формада мөрәҗәгать итүчегә шәхсән яисә почта аша;

электрон документ формасында электрон почта һәм (яки) мөрәҗәгать итүченең «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» дәүләт мәгълүмат системасындагы (алга таба – Портал) шәхси кабинетына җибәреп.

2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү срогы.

2.4.1. Гаризаны раслаган көннән башлап 60 календарь көн эчендә.

2.4.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.

2.4.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган боерык күчермәсе белән теркәлә торган хатны бирү (җибәрү) җылылык челтәрләре буенча җылылык энергиясен, җылылык тапшыру матдәсен тапшырганда технологик югалту нормативларын раслау турындагы боерыкны имзалаган һәм аны теркәгән көннән соң ике көн эчендә гамәлгә ашырыла.

2.4.4. Җылылык челтәрләре буенча җылылык энергиясен, җылылык җиткерү матдәсен тапшырганда технологик югалту нормативларын раслаудан баш тарту турындагы белдерүне мөрәҗәгать итүче күрсәткән ысул (почта, электрон почта адресы буенча) белән җибәрү баш тарту турында белдерү имзаланган көннән башлап ике көн эчендә гамәлгә ашырыла

2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен хокукый нигезләр.

Порталда, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (http://kt.tatarstan.ru) түбәндәгеләр урнаштырылган:

дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору өчен җаваплы органнар

(учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр;

дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, дәүләт яки муниципаль хезмәткәрләрнең, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат.

2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге.

2.6.1. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхсән тапшырыла торган, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар:

1) гариза (1 нче кушымта).

2) мөлкәтнең аренда шартнамәсе яки ия булу хокукын раслый торган бүтән документ.

3) Россия Федерациясе Энергетика министрлыгының 2008 елның 30 декабрендәге 325 номерлы боерыгы белән расланган Технологик югалту нормативларын билгеләү тәртибе (алга таба – Тәртип) нигезендә раслау өчен тапшырылган җылылык энергиясен тапшырганда, җылылык челтәрләре буенча җылылык энергиясен тапшыру матдәсен технологик югалту күрсәткечен нигезли торган документлар, асылда:

технологик югалту һәм җылылык энергиясен тапшыру матдәсен югалту нормативларының исәпләмәсе, шул исәптән планлы ремонтлардан соң эшләтеп җибәрер алдыннан җылылык челтәрләре торбаүткәргечләрен тутыруга киткән җылылык энергиясен тапшыру матдәсен сарыф итүләр, автомат җайга салу һәм яклау чаралары белән җылылык энергиясен тапшыру матдәсен технологик бушатулар, планлы эксплуатация сынауларына җылылык энергиясен тапшыру матдәсенең техник нигезләнгән сарыфы һәм җылылык челтәрләре арматурасында һәм торбаүткәргечләрендә тыгызлык булмаган урыннар аша котылып булмый торган җылылык энергиясен тапшыру матдәсен техник югалтулар (җылылык белән тәэмин итү системасының һәркасы өчен су, пар һәм конденсат җылылык энергиясен тапшыру матдәләре буенча аерым-аерым);

җылылык энергиясенең технологик сарыфларының һәм югалтуларның нормативлары исәпләмәсе, шул исәптән торбаүткәргечләрнең җылылык изоляциясе конструкцияләре аша да җылылык энергиясен тапшыру матдәләрен югалтулар белән (җылылык белән тәэмин итү системасының һәркайсы өчен су һәм пар җылылык челтәрләре буенча аерым);

җылылык энергиясен һәм җылылык энергиясен тапшыру матдәсен тапшыруга электр энергиясенең норматив технологик сарыфлары исәпләмәсе (җылылык белән тәэмин итү системасының һәркайсы өчен аерым);

нормативларны исәпләгәндә кулланыла торган методларга тасвирлама;

технологик сарыфларның нормативларын исәпләү буенча кулланыла торган программалар турында белешмәләр (программаның аталышы, аны эшләүченең исеме, кулланыла торган версиясенең эшләнгән елы, эксперт бәяләмәләренең, сертификатларның күчермәләре һ.б.);

агымдагы елга һәм бу елдан алдагы ике елга закон тәртибендә билгеләнгән нормативларның күрсәткечләре;

агымдагы елдан алдагы ике елда коммерция исәбе күрсәткечләре буенча

җылылык энергиясен тапшырганда җылылык энергиясен тапшыру матдәләренең, җылылык энергиясенең фактик югалту һәм электр энергиясен сарыф итү күрсәткечләре;

җайга салу елына, агымдагы елдан алдагы ике елга җылылык энергиясенә булган тарифларга кертелгән нормативларның күрсәткечләре (җылылык энергиясен тапшыру хезмәтләренә), тулаем алганда һәм җылылык белән тәмин итү системалары һәм «пар» (басымнары буенча) һәм «су» җылылык энергиясен тапшыру матдәләре буенча бүлеп;

җылылык энергиясен тапшырганда технологик югалту нормативларының әһәмиятен нигезләүче материалларга экспертиза бәяләмәсе.

3) аңлатма язуы, анда түбәндәгеләр булырга тиеш:

һәр җылылык белән тәэмин итү системасының җылылык энергиясе чыганаклары турында белешмәләр (Гкал/сәг (кайнар суда) һәм т/сәг (парда) җылылык энергиясе чыганакларының билгеләнгән һәм эш итә торган егәрлекләре);

җылылык белән тәэмин итү системаларына сыйфатламалар (җайга салу елына, агымдагы елга һәм агымдагы елдан алдагы ике елга), шул исәптән:

кайнар су белән тәэмин итүгә һәм җылытуга - вентиляциягә, технологик ихтыяҗларга исәпләнгән тоташтырылган басымнар (Гкал/сәг);

эксплуатацион температура графиклары;

җылылык энергиясен җибәрү һәм куллану турында белешмәләр (мең Гкал/ел);

һәр җылылык челтәре буенча озынлыгы, җылыту һәм җылытмый торган чорда җылылык челтәрләре торбаүткәргечләренең күләмнәре, торбаүткәргечләрнең җылылык изоляцияләү тибы, җылылык челтәрләрен эксплуатациягә кертү еллары турында белешмәләр;

җылылык энергиясен тапшыру матдәсенең, грунтның, тышкы һаваның, чыга торган, җылылык челтәрләрен туендыру өчен кулланыла торган суның җылыту һәм җылытмый торган чорларда уртача еллык һәм уртача күрсәткечләре;

җылыту һәм җылытмый торган чорда һәр җылылык челтәренең функцияләү озынлыгы, планлы ремонтлар уздыру һәм җылылык челтәрләрендә эксплуатацион сынаулар өчен өзеклекләрнең озынлыгы;

кулланыла торган егәрлек күләме, мөрәҗәгать итүче тарафыннан эксплуатацияләнә торган, җылылык энергиясен тапшырганда кулланыла торган насос һәм башка электрлаштырылган җайланманың файдалы җибәрү коэффициентлары турында белешмәләр, күрсәтелгән җайланмага сыйфатламалар, җылыту һәм җылытмый торган чорларда суыртыла торган җылылык энергиясен тапшыру матдәсе сарыфларының һәм җылылык челтәренең эксплуатацион гидравлик эш режимы нигезендә насос төркемнәре буенча барлыкка килүче этемнәрнең уртача күрсәткечләре, җайга салу чорында күрсәтелгән җайланмадан файдалану озынлыгы;

исәпләнгән тоташтырылган җылылык басымы 50 Гкал/сәг һәм аннан күбрәк тәшкил иткән җылылык челтәрләренең җайга салу чоры башланырга биш елдан иртәрәк булмаган чорда төзелгән норматив энергетика

сыйфатламалары, шулай ук норматив энергетика сыйфатламаларын эшләгәндә җайга салу чорына фаразданган башлангыч белешмәләрне төзү нәтиҗәләре;

җайга салу чоры башланырга кимендә биш ел эчендә уздырылган җылылык челтәрләренә энергетика тикшеренүләре хисаплары һәм нәтиҗәләре;

оешманың тиешле инвестиция программасы нигезендә җылылык челтәре буйлап җылылык энергиясен тапшырганда технологик югалтуларны киметүгә юнәлдерелгән энергияне сак куллану чаралары исемлеге;

җылылык челтәрләре буйлап җылылык энергиясенең, җылылык энергиясен тапшыру матдәсенең югалу нормативлары күрсәткечләрен нигезләүче материалларга экспертиза буенча бәяләмә.

Аларны таныклау шарты белән, документларның күчермәләрен аларның төп нөсхәләре урынына тапшыру рөхсәт ителә.

Документларда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган бетерелгән, өстәп язылган урыннар, сызылган сүзләр һәм төзәтмәләр булу - рөхсәт ителми.

Дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен гариза бланкын Мөрәҗәгать итүче Дәүләт комитетына шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Дәүләт комитетының рәсми сайтында урнаштырылган.

Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсе аша тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:

шәхсән (ышаныч кәгазе нигезендә мөрәҗәгать итүче исеменнән эш итүче зат тарафыннан);

почта аша.

Гариза һәм документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон документ рәвешендә тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:

гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән «Интернет» челтәре аша;

Портал аша.

Гариза‍ны һәм кирәкле документларны гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, шул исәптән «Интернет» челтәре аша да җибәргән очракта, гариза һәм электрон документ формасындагы документларның күчермәләре «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон) таләпләре нигезендә имзаланырга (расланган булырга) тиеш.

2.6.2. Гариза‍ны һәм кирәкле документларны Портал аша җибәргән очракта, мөрәҗәгать итүче гариза‍ны гади электрон имза белән имзалый.

Гади электрон имза алу өчен мөрәҗәгать итүчегә электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә файдаланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик багланышларын тәэмин итә торган инфраструктурада бердәм идентификация һәм аутентификация системасында теркәлү (аутентификация) процедурасын узарга, шулай ук стандарттан ким булмаган дәрәҗәгә кадәр исәпкә алу язуын да расларга кирәк.

2.6.3. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алына торган

документлар (белешмәләр) таләп ителми.

2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге.

Документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре:

Мөрәҗәгать итүче булып тормаган, әлеге Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелмәгән затның документлар белән мөрәҗәгать итүе.

2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге.

2.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр юк.

2.8.2. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан тиешле хәбәр алынганнан соң 30 календарь көне эчендә җитешмәгән һәм (яки) эшләнеп бетмәгән документларның тапшырылмавы дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары.

Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатьне тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артык булырга тиеш түгел.

Югарыда күрсәтелгән чират көтү вакытына төшке тәнәфес һәм эш вакыты булып саналмаган вакыт кертелми.

Дәүләт хезмәтеннән файдаланучы аерым категорияләр өчен чират билгеләнмәгән.

2.11. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгатен теркәүгә алу чоры.

Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мөрәҗәгате кирәкле барлык документлары белән гариза алынган көнне теркәлә.

Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән рәсми мөрәҗәгать ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә.

2.12. Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр.

2.12.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.

2.12.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла. Көтү залларында (бүлмәләрдә) дәүләт хезмәте күрсәтү турында мәгълүматлар, шулай ук аларны тутыру үрнәкләре белән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза үрнәкләре урнаштырылган мәгълүмат стендлары урнаштырыла.

2.12.3. Инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларда (алга таба – Объект) законнар һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән

таләпләргә туры китереп, түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) Объектлардан һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән каршылыксыз файдалана алу шартлары;

б) территория буенча мөстәкыйль рәвештә яки дәүләт хезмәте күрсәтә торган хезмәткәрләр ярдәмендә хәрәкәт итү, мондый Объектларга керү һәм алардан чыгу мөмкинлеге;

в) Объектларга керә торган урында транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм, кирәк булганда, дәүләт хезмәте күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәмендә дә;

г) күрү сәләте һәм мөстәкыйль хәрәкәт функциясе бозылган инвалидларны озатып бару һәм аларга Объектларда ярдәм күрсәтү;

д) инвалидларның Объектлардан һәм күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләреннән каршылыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат җиһазларын тиешенчә урнаштыру;

е) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле, тавыш ярдәмендә һәм күрсәтмә мәгълүматны, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм Брайль рельеф-нокта шрифтлары белән һәм контраст фонында башкарылган текстлы һәм графиклы башка мәгълүматны кабатлап күрсәтү, сурдотәрҗемәчене, тифлосурдотәр-җемәчене, шулай ук ишарә телен белә торган башка затны кертү;

ж) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июлендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, Объектларга сукырларны озата йөри торган этне кертү;

з) дәүләт хезмәте күрсәтүче хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга алар өчен үтемле формада дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен аңлатуга, аны күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерүгә, инвалидларны кабинетларның урнаштырылу тәртибе белән таныштуыруга, дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле гамәлләр эзлеклелегенә бәйле кирәкле ярдәмне күрсәтү;

и) инвалидларның яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, электрон рәвештә дәүләт хезмәтләреннән файдалана алу мөмкинлеге;

к) дәүләт хезмәте күрсәтүче хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә дәүләт хезмәтеннән файдалануга комачау итә торган каршылыкларны үтүдә кирәкле башка ярдәм күрсәтү.

2.12.4. 2016 елның 1 июленнән соң капиталь ремонт, реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итү өлешендәге таләпләр.

2.13. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлекле һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре.

2.13.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

документларны кабул итү һәм карау чорларының саклануы;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу чорының саклануы;

дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан әлеге Регламент бозылу очракларына карата нигезле шикаятьләрнең булмавы;

мөрәҗәгать итүченең Дәүләт комитеты белгечләре белән шәхси мөрәҗәгать иткәндә үзара бәйләнешкә керү саны икедән артмый (консультацияләрне исәпкә алмыйча).

2.13.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

документларны кабул итү, тапшыру эшләре башкарыла торган биналарның җәмәгать транспортыннан файдалана алу зонасында урнашуы;

белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган урыннарның кирәкле санда булуы;

дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм вакытлары турында мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендәге мәгълүмат ресурсларында, Порталда тулы мәгълүмат булуы;

дәүләт хезмәте күрсәтә торган хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә дәүләт хезмәтләреннән файдалануга комачаулый торган каршылыкларны үтеп чыгарга ярдәм итү.

2.13.3. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең Дәүләт комитеты белгече белән бер мәртәбә бәйләнешкә керү вакыты 15 минуттан артмый.

2.13.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү барышы турындагы мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Порталдан алынырга мөмкин.

2.13.5. Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми.

2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә башка таләпләр, шул исәптән: күпфункцияле үзәкләрдә дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган; Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте турында белешмәләр бирү турында.

2.14.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.14.2. Гаризаны электрон документ рәвешендә Портал (http://uslugi.tatarstan.ru) аша тапшыру мөмкинлеге бар.

2.14.3. Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүче хокуклы:

а) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Порталда урнаштырылган мәгълүматны алырга;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон үрнәкләре элегрәк 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә таныкланган документларны һәм мәгълүматны да, Порталдан файдаланып тапшырырга;

в) электрон формада тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаларны үтәү барышы турында белешмәләр алырга;

г) Порталдан файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатына бәя

бирергә;

д) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алырга;

е) Портал, дәүләт хезмәтләре күрсәтә торган органнар, аларның вазыйфаи затлары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кабул ителгән карарларга һәм кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы ярдәмендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты, шулай ук аның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять бирергә.

2.14.4. Гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Порталда гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

2.14.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә Дәүләт комитеты рәсми сайтында (http://kt.tatarstan.ru) һәм Порталда (http://uslugi.tatarstan.ru/) урнаштырыла.

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәлү сроклары.

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә һәр административ процедураның (гамәлнең) тасвирламасы.

Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, шул исәптән гариза төзү өлешендә дә;

гаризаны теркәлгән документлары белән кабул итү һәм теркәү;

мөрәҗәгать итүче тапшырган материалларны эшкәртү барышында документларның билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерү;

исәпләмәләргә һәм тапшырылган материалларга анализ, җылылык энергиясен, җылылык энергиясен саклаучы матдә тапшырылганда технологик югалту нормативларын раслау турында карар кабул итү;

мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен юллау;

техник хатаны төзәтү.

3.2. Мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән гаризаны төзү өлешендә дә.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен Дәүләт комитетына шәхсән, телефон, электрон почта һәм (яисә) «Татарстан Республикасы рәсми порталының «Интернет-кабул итү» системасы» аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Технологик аудит бүлеге (алга таба – Бүлек) белгече шәхсән, телефон, электрон почта аша, язмача һәм (яки) хат аша мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән гаризаның составы, формасы һәм эчтәлеге һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен башка мәсьәләләрдә дә, шулай ук, кирәк булганда, гариза рәсмиләштерүдә ярдәм күрсәтә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гаризаның һәм тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм башка мәсьәләләрдә консультация, шулай ук күрсәтелгән ярдәм.

3.3. Гаризаны теркәлгән документлары белән кабул итү һәм теркәү.

Мөрәҗәгать итүче шәхсән, ышанычлы заты аша яки почта, Татарстан Республикасы рәсми порталының Интернет-кабул итү системасы, Портал аша җылылык челтәрләре буенча җылылык энергиясен, җылылык энергиясен саклаучы матдә тапшырылганда технологик югалту нормативларын раслау турында гаризаны Дәүләт комитетының гомуми тәэмин итү һәм эшчәнлек бүлегенә тапшыра һәм әлеге Регламентның 2.6 пункты нигезендә документлар тапшыра.

Процедураның нәтиҗәсе: тапшырылган гариза һәм документлар.

3.3.1. Портал аша электрон формада гариза тапшыру өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәге гамәлләрне башкара:

Порталда авторизацияләнә;

Порталда гаризаның электрон формасын ача;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;

электрон формадагы документларны яки электрон документ үрнәкләрен электрон гариза формасына беркетә (кирәк булганда);

электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм килешү фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле тамга билгели);

хәбәр ителгән белешмәләрнең дөреслеген раслый (электрон гариза рәвешендә тиешле тамга билгели);

тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза рәвешендәге тиешле төймәгә баса);

электрон гариза әлеге Регламентның 2.6.2 пункты таләпләре нигезендә имзалана;

электрон гаризаның җибәрелүе турында белдерү ала.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: Дәүләт комитетына Портал аша җибәрелгән электрон эш. Электрон гариза Бүлек белгече өчен файдалана алырлык була.

3.3.2. Гомуми тәэмин итү һәм эшчәнлек бүлеге белгече:

гариза белән документларны кабул итә;

гаризаны беренчел эшкәртә һәм «Электрон Хөкүмәт» Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының электрон документ әйләнеше буенча бердәм ведомствоара системасында (алга таба – электрон документ әйләнеше) теркәү номерын беркетеп һәм кабул итү датасын күрсәтеп терки;

документларны кабул итү датасы, беркетелгән кереш номеры, дәүләт хезмәте күрсәтүнең датасы һәм вакыты турында тамгалап, гариза күчермәсен почта буенча яки электрон почта (ихтыярына карап) аша гариза бирүчегә тапшыру яки җибәрү;

гаризаны Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисенә (алга таба – рәис) яки аның вазыйфаларын башкаручы затка электрон документлар әйләнеше системасы аша электрон формада җибәрү.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза алынган көнне башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм рәискә яисә аның вазыйфаларын башкаручы затка юнәлдерелгән гариза һәм документлар.

Әлеге Регламентның 2.7 пунктында каралган нигезләр булган очракта, гомуми тәэмин итү һәм эшчәнлек бүлеге белгече, документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген язмача аңлатып, мөрәҗәгать итүчегә гаризаны һәм документларны кире кайтара.

Процедура гариза алынган көнне башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кире кайтарылган гариза һәм документлар.

3.3.3. Рәис яки аның вазыйфаларын башкаручы зат гаризаны карый һәм Бүлекне алып баручы рәис урынбасарына (алга таба – рәис урынбасары) карау

өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны теркәгән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: рәис урынбасарына карау өчен җибәрелгән гариза.

3.3.4. Рәис урынбасары гаризаны карый һәм Бүлек җитәкчесенә карап тикшерү өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны теркәгән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: бүлек җитәкчесенә карап тикшерүгә җибәрелгән гариза.

3.3.5. Бүлек җитәкчесе гаризаны һәм документларны карый, җаваплы башкаручыны (алга таба – Бүлек белгече) билгели һәм карау өчен аңа җибәрә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач бер календарь көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Бүлек белгеченә юлланган гариза һәм документлар.

3.4. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документларны билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәүгә карата тикшерү.

Бүлек белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

җылылык челтәрләре буйлап җылылык энергиясен, җылылык энергиясен тапшыру матдәсен тапшырганда технологик югалту нормативларын раслау турында эш формалаштыру (барлык документларны бер папкага туплау);

документларның әлеге Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән исемлеккә туры килү-килмәве буенча һәм нормативлар буенча документларның дөрес рәсмиләштерелгән булу-булмавын: комплектлылыгын, күрсәтелгән кушымталары булуын, таныклый торган реквизитлары (имза, штамп, теркәлү номеры, фамилиясе һәм мөрәҗәгать итүченең телефон номеры) булуын, гариза тутыруның төгәл булу-булмавын тикшерә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар аннан алдагы процедуралар тәмамлангач ике көн дәвамында башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тикшерелгән документлар.

3.5. Кисәтүләрне бетерү кирәклеге турында гариза бирүчегә хәбәр әзерләү һәм җибәрү.

3.5.1. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан документларның тулы булмаган комплект белән җибәрелгән очракта яки алар Тәртип таләпләренә туры килмәгәндә, шулай ук техник хаталары булган яки рәсмиләштерелүе билгеләнгән таләпләргә туры килми торган документлар җибәрелгәндә Бүлек белгече кисәтүләрне бетерү һәм җитешмәгән һәм (яки) кисәтүләрен исәпкә алып эшләп бетерелгән документларны Дәүләт комитетына җибәрү зарурлыгы турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәрне (алга таба – хәбәр) килештерү өчен Бүлек җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар аннан алдагысы тәмамланган көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кисәтүләрне бетерү зарурлыгы турында

имзаланган хәбәр.

3.5.2. Бүлек җитәкчесе хәбәрне карый, килештерә һәм аны рәис урынбасарына килештерү өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар аннан алдагысы тәмамланган көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кисәтүләрне бетерү зарурлыгы турында килештерелгән хәбәр.

3.5.3. Рәис урынбасары, хәбәрне карап, аңа кул кую турында карар кабул итә һәм аны гомуми тәэмин итү һәм эшчәнлек бүлегенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар аннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер календарь көне дәвамында башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кисәтүләрне бетерү зарурлыгы турында имзаланган хәбәр.

3.5.4. Гомуми тәэмин итү һәм эшчәнлек бүлеге белгече хәбәрне терки һәм мөрәҗәгать итүчегә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар аннан алдагысы тәмамланган көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кисәтүләрне бетерү зарурлыгы турында мөрәҗәгать итүчегә җибәрелгән хәбәр.

3.5.5. Әлеге Регламентның 2.8 пунктында билгеләнгән нигезләр булган очракта, Бүлек белгече, Бүлек җитәкчесе белән алдан килештереп, рәис урынбасарыннан имзалатып җылылык челтәрләре буенча җылылык энергиясе, җылылык энергиясен саклый торган матдә тапшырылганда технологик югалту нормативларын раслаудан баш тарту турында белдерү әзерли һәм аны гомуми тәэмин итү һәм эшчәнлек башкару бүлегенә җиткерә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче тарафыннан кисәтүләрне бетерү срогы беткән вакыттан башлап бер календарь көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: җылылык челтәрләре буенча җылылык энергиясен, җылылык энергиясен саклый торган матдә тапшырылганда технологик югалту нормативларын раслаудан баш тарту турында хәбәр.

3.5.6. Гомуми тәэмин итү һәм эшчәнлек бүлеге белгече җылылык энергиясе, җылылык энергиясен саклый торган матдә тапшырылганда технологик югалту нормативларын раслаудан баш тарту турында хәбәрне терки һәм җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура рәис урынбасары хәбәргә кул куйган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: теркәлгән, мөрәҗәгать итүчегә җибәрелгән хәбәр.

3.6. Исәпләмәләргә һәм тапшырылган материалларга анализ, җылылык энергиясен, җылылык энергиясен саклаучы матдә тапшырылганда технологик югалту нормативларын раслау турында карар кабул итү.

3.6.1. Документлар комплектына искәрмәләр булмаган очракта яки мөрәҗәгать итүче тарафыннан кисәтүләрне бетергәннән соң, Бүлек белгече тапшырылган материалларны һәм исәпләмәләрне Тәртиптә билгеләнә торган

таләпләргә туры килү-килмәве буенча анализлый һәм җылылык челтәрләре буйлап җылылык энергиясе, җылылык энергиясен саклый торган матдә тапшырылганда технологик югалту нормативларын раслау турында боерык проектын әзерли һәм аны килештерү өчен Бүлек җитәкчесенә, юридик бүлек җитәкчесенә, гомуми тәэмин итү һәм эшчәнлек бүлеге җитәкчесенә һәм рәис урынбасарына юллый.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.4 пунктында күрсәтелгән процедуралар тәмамлангач илле эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: җылылык челтәрләре буенча җылылык энергиясе, җылылык энергиясен саклый торган матдә тапшырылганда технологик югалту нормативларын раслау турында боерык проекты

3.6.2. Бүлек җитәкчесе, юридик бүлек җитәкчесе, гомуми тәэмин итү һәм эшчәнлек бүлеге җитәкчесе һәм рәис урынбасары боерык проектын карый, килештерә һәм имзалау өчен рәискә яки аның вазыйфаларын башкаручы затка җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар аннан алдагы процедуралар тәмамлангач өч көн дәвамында башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Бүлек җитәкчесе, юридик бүлек җитәкчесе, гомуми тәэмин итү һәм эшчәнлек бүлеге җитәкчесе һәм рәис урынбасары белән килештерелгән, җылылык челтәрләре буенча җылылык энергиясе, җылылык энергиясен саклый торган матдә тапшырылганда технологик югалту нормативларын раслау турында рәискә яисә аның вазыйфаларын башкаручы затка имзалау өчен җибәрелгән боерык проекты.

3.6.3. Рәис яки аның вазыйфаларын башкаручы зат җылылык челтәрләре буенча җылылык энергиясе, җылылык энергиясен саклый торган матдә тапшырылганда технологик югалту нормативларын раслау турындагы боерыкны карый, имзалый һәм гомуми тәэмин итү һәм эшчәнлек бүлегенә җибәрә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач бер көн дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: имзаланган боерык.

3.6.4. Бүлек белгече боерык күчермәсен имза кую өчен рәис урынбасарына җибәрү өчен, бүлек җитәкчесе белән алдан килештереп, теркәү хатын әзерли.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач бер көн дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: җылылык челтәрләре буенча җылылык энергиясе, җылылык энергиясен саклый торган матдә тапшырылганда технологик югалту нормативларын раслау турында боерык күчермәсе белән теркәү хаты проекты

3.6.5. Рәис урынбасары Бүлек җитәкчесе белән алдан килештереп, теркәү хатына кул куя.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач бер көн дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: боерык күчермәсе белән теркәү хаты яки җылылык челтәрләре буенча җылылык энергиясе, җылылык энергиясен саклый торган матдә тапшырылганда технологик югалту нормативларын раслаудан баш тарту турында хәбәр.

3.6.6. Гомуми тәэмин итү һәм эшчәнлек бүлеге белгече:

җылылык челтәрләре буенча җылылык энергиясе, җылылык энергиясен саклый торган матдә тапшырылганда технологик югалту нормативларын раслау турында боерык белән теркәү хатын терки;

җылылык челтәрләре буйлап җылылык энергиясен, җылылык энергиясен саклый торган матдә тапшырылганда технологик югалту нормативларын раслау турында боерык күчермәсе белән бергә теркәү хатын мөрәҗәгать итүчегә почта буенча җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар теркәү хаты имзаланган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: җылылык челтәрләре буенча җылылык энергиясе, җылылык энергиясен саклый торган матдә тапшырылганда технологик югалту нормативларын раслау турында боерык күчермәсе белән мөрәҗәгать итүчегә җибәрелгән теркәү хаты.

3.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документта техник хата ачыкланган очракта, мөрәҗәгать итүче Дәүләт комитетына түбәндәгеләрне тапшыра:

техник хатаны төзәтү турында гариза (3 нче кушымта);

мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак тапшырылган, техник хатасы булган документ;

техник хатасы барлыгын дәлилли торган, юридик көчкә ия документлар.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документ мәгълүматларындагы техник хатаны төзәтү турында гариза мөрәҗәгать итүче (вәкаләтле вәкил) тарафыннан шәхсән тапшырыла яисә почта аша, электрон почта ярдәмендә яисә Портал аша җибәрелә.

3.7.1. Документларны кабул итү өчен җаваплы гомуми тәэмин итү һәм эшчәнлек белгече техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итә, гаризаны теркәп тапшырылган документлары белән бергә терки һәм аларны Бүлеккә тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны теркәгәннән соң бер көн эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, Бүлек белгеченә карап тикшерүгә җибәрелгән гариза.

3.7.2. Бүлек белгече документларны карап тикшерә һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документка үзгәрешләр кертү максатларында шушы Регламентта каралган процедураларны башкара һәм яңадан үзгәртеп рәсмиләштерелгән документны мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкилгә) шәхсән имзалатып, мөрәҗәгать итүчедән (вәкаләтле вәкилдән) техник хатасы булган документның чын нөсхәсен алып калып тапшыра яки Мөрәҗәгать итүче адресына почта (электрон почта) аша, Бүлеккә техник хатасы булган документның чын нөсхәсен тапшырган очракта, документны алу мөмкинлеге

турында хат җибәрә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура техник хата ачыкланган вакыттан башлап яисә теләсә кайсы кызыксынган заттан җибәрелгән хата турында гариза алынганнан соң өч көн дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә бирелгән (почта яки электрон адрес буенча җибәрелгән) җавап.

## 4. Административ регламент үтәлешен контрольдә тоту формалары

4.1. Дәүләт комитеты вазыйфаи затларының әлеге Регламенттагы һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүгә таләпләр билгели торган бүтән норматив хокукый актлардагы нигезләмәләрне үтәвен һәм башкаруын, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул ителүне тикшереп тору тиешле административ процедураны үтәү өчен җаваплы зат һәм Дәүләт комитетының дәүләт хезмәте күрсәтү буенча эшне оештыру өчен җаваплы булган заты һәм рәис урынбасары тарафыннан әлеге Регламент нигезләмәләрен үтәү һәм башкаруга карата тикшерүләр уздыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

4.2. Административ регламент үтәлешен контрольдә тоту Дәүләт комитетының дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган вазыйфаи затлары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.3. Агымдагы контрольлек Дәүләт комитеты вазыйфаи затларының Регламентта һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган башка норматив хокукый актлардагы нигезләмәләрне үтәвенә һәм башкаруына тикшерүләр уздыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Агымдагы тикшереп тору даими нигездә гамәлгә ашырыла.

4.4. Административ регламентны үтәүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшереп тору, гариза тапшыручыларның хокуклары бозылуны ачыклау һәм бетерү, карарлар кабул итү һәм мөрәҗәгать итүчеләрнең Дәүләт комитеты вазыйфаи затлары карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелгән мөрәҗәгатьләренә җавап әзерләү.

4.5. Административ регламентны үтәүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшерү Дәүләт комитеты актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Тикшерүләр планлы (Дәүләт комитетының еллык эш планы нигезендә гамәлгә ашырыла торган) һәм планнан тыш булырга мөмкин.

4.6. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын планнан тыш тикшерү турында карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) Регламенттагы һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган норматив хокукый актлардагы таләпләрне бозуның элек ачыкланган очракларын юкка чыгаруны тикшерүгә бәйле рәвештә;

2) юридик затлар Дәүләт комитетының дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган вазыйфаи затлары гамәлләренең (гамәл кылмавы) үзләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуга бәйле шикаятьләр белән мөрәҗәгать иткәндә.

4.7. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшерү нәтиҗәләре акт белән рәсмиләштерелә, анда ачыкланган җитешсезлекләр һәм аларны юкка чыгару буенча тәкъдимнәр теркәлә.

4.8. Тикшереп тору нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланганда, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.9. Административ регламент үтәлешен контрольдә тоту гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Дәүләт комитеты эшчәнлегенең ачыклыгы, дәүләт хезмәте

күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм ышанычлы мәгълүмат алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәрге тәртиптә карау мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Мөрәҗәгать итүчеләр Дәүләт комитетының, Дәүләт комитеты вазыйфаи затының йә Дәүләт комитеты дәүләт хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәрге тәртиптә Дәүләт комитетына шикаять белдерергә хокуклы. Дәүләт хезмәте күрсәтелүгә бәйле рәвештә рәис карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тапшырыла.

5.2. Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны, 210-ФЗ номерлы федераль законның $15^1$ статьясында күрсәтелгән рәсми мөрәҗәгатьне теркәү срогы бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү чоры бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәте күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы каралмаган документларны яки мәгълүматларны тапшыру яисә гамәлләр башкару таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартылганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

6) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алынуы каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) Дәүләт комитетының, аның вазыйфаи затының дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда үзләре тарафыннан җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогы яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган очраклардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүматны таләп ителгәндә.

5.3. Шикаять почта буенча, күпфункцияле үзәк аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен, Дәүләт комитетының рәсми сайтын (http://kt.tatarstan.ru), Порталны (http://uslugi.tatarstan.ru) кулланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул итү вакытында да алынырга мөмкин.

5.4. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган вазыйфаи затының яисә граждан хезмәткәренең, аның җитәкчесенең һәм (яки) хезмәткәренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турындагы белешмәләр, мөрәҗәгать итүче – юридик затның атамасы, урнашкан урыны турындагы белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яисә дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелгән карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яисә дәүләт хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезләүче дәлилләр.

5.5. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.6. Шикаять алынган көненнән соңгы эш көне узганчы теркәлергә тиеш.

Шикаятьләрне карау чоры – аны теркәүгә алганнан соң унбиш эш көне эчендә карала һәм Дәүләт комитетының мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү рәвешендә дә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

5.8. 5.5 пунктның 1һәм 2 пунктчаларында күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң килә торган көннән соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язмача яисә, аның ихтыяры буенча, электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

5.9. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, җавапта әлеге пунктта күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында Дәүләт комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану максатларында алга таба мөрәҗәгать итүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.10. Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта, әлеге пунктта күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.11. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

5.12. Дәүләт комитеты, шулай ук аның вазыйфаи затлары, яки дәүләт граждан хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләр 210-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә җайга салына.

Халкының исәбе биш йөз һәм аннан күбрәк кеше исәпләнгән авыл җирлекләрендә, шәһәр округларында урнашкан җылылык челтәрләреннән тыш, җылылык челтәрләре буенча җылылык энергиясе, җылылык энергиясен саклый торган матдә тапшырылганда технологик югалту нормативларын раслау буенча Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
1 нче кушымта

Киңәш ителә торган форма

Оешманың фирма бланкында
(оешманың реквизитлары)

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитеты рәисенә
_______________________________
(инициаллар, фамилия)

ГАРИЗА

Милекчелек хокукында яки законлы бүтән нигезләрдә җылылык челтәрләре буйлап җылылык энергиясен, җылылык энергиясен тапшыру матдәсен тапшырганда технологик югалту нормативларын раслауны сорыйм

__________________________________________________________________
(оешма атамасы)

Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек башкара

__________________________________________________________________
(торак пункт, муниципаль район аталышы)

тарифларны дәүләти җайга салу чорына ________________ ел.
(җайга салу чорын күрсәтергә)

Кушымта: _______________________________________________
(теркәлүче документларны кыскача тасвирлау)

__________________________ ____________ ________________________
(җитәкченең вазыйфасы) (имза) (Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта))

Мөһер урыны (булган очракта)

Халкының исәбе биш йөз һәм аннан күбрәк кеше исәпләнгән авыл җирлекләрендә, шәһәр округларында урнашкан җылылык челтәрләреннән тыш, җылылык челтәрләре буенча җылылык энергиясе, җылылык энергиясен саклый торган матдә тапшырылганда технологик югалту нормативларын раслау буенча Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт
комитеты рәисенә
________________________________
(инициаллар, фамилия)

ГАРИЗА
техник хата төзәтү турында

Җылылык челтәрләре буйлап җылылык энергиясе, җылылык энергиясен саклый торган матдә тапшырылганда технологик югалту нормативларын раслау буенча дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының _______________ № ______ боерыгында җибәрелгән хата турында хәбәр итәм.

Язылган:____________________________________________________________

Дөрес белешмәләр:___________________________________________________

Техник хатаны төзәтүегез һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган боерыкка тиешле үзгәрешләрне кертүегез турында үтенәм.

Түбәндәге документларны терким:

1. ___________________________________________________________________;
2. ___________________________________________________________________;
3. ___________________________________________________________________.

Техник хатаны төзәтү турында гаризаны кире кагу турында карар кабул ителгән очракта мондый карарны:

түбәндәге адреска документ җибәрү юлы белән: ____________________;

_____________________________________________________________ адресы буенча кәгазьдәге документның таныкланган күчермәсе рәвешендә почта аша җибәрүне сорыйм.

Халкының исәбе биш йөз һәм аннан күбрәк кеше исәпләнгән авыл җирлекләрендә, шәһәр округларында урнашкан җылылык челтәрләреннән тыш, җылылык челтәрләре буенча җылылык энергиясе, җылылык энергиясен саклый торган матдә тапшырылганда технологик югалту нормативларын раслау буенча Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (белешмәлек) кушымта

Җылылык энергиясе, җылылык энергиясен саклый торган матдә тапшырылганда технологик югалту нормативларын раслау буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган һәм дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерүдә тоту өчен җаваплы вазыйфаи затларның реквизитлары

Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты

| Фамилия, исем, ата исеме вазыйфасы | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе | 221-82-18 | kt@tatar.ru |
| Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары | 221-82-02 | Pavlov.SV@tatar.ru |
| Технологик аудит бүлеге җитәкчесе | 221-82-28 | Ramil.Minnullin@tatar.ru |
| Гомуми тәэмин итү һәм эшчәнлек бүлеге белгече | 221-82-94 | kt@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Төзелеш, транспорт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыгы идарәсенең торак-коммуналь хуҗалык һәм транспорт бүлеге җитәкчесе | 264-76-02 | Fail.Salihov@tatar.ru |